Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегенең Күләгәш торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019ел, 09 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Күләгәш торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Күләгәш авыл җирлеге Күләгәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасы шоферына түләү
- Күләгәш авылының Пионерская,Урман урамнарын ремонтлау һәм вак ташу салу.
- Күләгәш авылы урамнарын кардан чистарту.

3.Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Күләгәш авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет Рәисе Ю.Н. ВАСИЛЬЕВ